ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 460-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Тыгин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 460-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2136-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 5 өлешендә «ул» сүзеннән соң «, әлеге Законның 5 статьясындагы $3^1$ өлешендә каралган очракта, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарларга (материалларга һәм җайланмаларга, шул исәптән югары технологияле җайланмаларга) түләү өчен, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:
«$3^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты региональ операторга аның счетында булдырыла торган, күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финансланучы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) сатып алу вәкаләтен, шулай ук сатып алынган һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга файдаланылмаган мондый товарларны (материалларны һәм җайланмаларны, шул исәптән югары технологияле җайланмаларны) реализацияләү вәкаләтен бирү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;
б) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Әлеге статьяның $3^1$ өлешендә каралган очракта, региональ оператор күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) сатып алуны, шулай ук сатып алынган һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга файдаланылмаган товарларны (материалларны һәм җайланмаларны, шул исәптән югары технологияле җайланмаларны) реализацияләүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра. Бу чакта региональ оператор функцияләренә Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясындагы $1^2$ өлешендә каралган функцияләр керә.»;

в) 5 өлештә «финанслау» сүзеннән соң «, шул исәптән, әлеге статьяның $3^1$ өлешендә каралган очракта, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарларга (материалларга һәм җайланмаларга, шул исәптән югары технологияле җайланмаларга) түләү» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 433-ФЗ номерлы Федераль закон белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләр башкару өчен кирәкле товарларны (материалларны һәм җайланмаларны, шул исәптән югары технологияле җайланмаларны) үзәкләштерелгән рәвештә сатып алуны тәэмин итү механизмы беркетелде. Бу максатларда Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органының региональ операторга капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финансланучы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) сатып алу вәкаләтен, шулай ук сатып алынган һәм капиталь ремонт ясауга файдаланылмаган мондый товарларны реализацияләү вәкаләтен бирү турында карар кабул итү хокукы билгеләнде.

Мондый карарны кабул итү очрагында региональ оператор тарафыннан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен үзе сатып алган һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга файдаланылмаган кирәкле товарларны (материалларны һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмаларны) реализацияләүдән акчалар капиталь ремонт фондын булдыра торган акчалар составына кертеләчәк.

Региональ оператор товарларны сатып алуны, шулай ук сатып алынган һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга файдаланылмаган товарларны реализацияләүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырачак.

Закон проекты белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына региональ операторга югарыда күрсәтелгән вәкаләтләрне бирү турында карар кабул итү хокукын беркетеп, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.